СЫЕРГА ДА КИРӘК
Мал-туарны вакцина белән генә саклап була

> 2

ӨЙДӘ ӘЙТСӘЛӘР
Балаларга прививка ясату өчен әти-әни рөхсәте кирәк булачак

> 2

НАДЕЖДА АЛЕКСЕЕВА:
«Кул эшләренә урын эзлим»

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 9 (28782) | Шимбә | 22 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

МӘСКӘҮНЕ ДӘ УЗГАННАР

Нәтиҗә

Тән саулыгы – бер хәл, рух ныклыгы югалмасын. Татарстан Мәдәният министрлыгының йомгаклау утырышында җан азыгының әһәмияте һәм ул җитәрлек булсын өчен ниләр башкарылганы турында хисап тоттылар.

Бу җәһәттән республикада күп нәрсәләр эшләнә дип әйтеп була инде анысы. Әнә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов та бит Татарстан – төрле яклап, шул исәптән мәдәният һәм сәнгать ягыннан да, кайнап торган төбәк, ди. Шуңа да елның иң әһәмиятле мәдәни вакыйгасы нинди дип аерып әйтерлек тә түгел. Булганнары барысы да кирәкле һәм әһәмиятле.

– Әгәр дә республика тормышын аерым вакыйгаларга бүлеп карарга тырышсак, дөрес булмас. Татарстандагы һәр көнебез иҗади рухта һәм иҗади эчтәлектә үтә. Республиканың мәдәният учреждениеләре, һөнәр осталары, сәнгатькәрләр кызу барган тормышыбызга үз өлешен кертә. Милли мәдәниятебезне саклау өлкәсендә дә тирән эчтәлектәге эш бара, – дип фикерләре белән уртаклашты ул коллегия утырышы алдыннан.

Тармак эшчәнлегенә бәйле төп нәтиҗәләр хакында мәдәният министры Ирада Әюпова үзе сөйләде. Күп юнәлешләрдә алдынгылыкка чыкканнар, шул ук вакытта игътибарга аласы мәсьәләләр дә бихисап.

Министр ил күләмендә 2022 елның Россия халыклары мәдәни мирасы елы дип игълан ителүен дә искә төшерде. Татарстан өчен бу аерым әһәмияткә ия ел булачак. «Дөнья дәрәҗәсендә әһәмиятле чара күтәрелә. Бу елның июнь аенда Казанга 194 илдән кунаклар киләчәк. Алар ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясенә җыелачак. Моңа өстәп, быел Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы да билгеләп үтелә», – диде ул.

Мәскәүне дә уздырганнар. Ил күләмендә гамәлгә ашырылучы «Пушкин картасы» проекты кысасында мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә билет сату буенча Татарстан алдынгы булган.

tatarstan.ru

Барлыгы 1,7 млрд сумга 2,5 млн билет сатылган. «Мәскәүне узу кыен, әмма без моны эшли алдык», – диде министр. Бигрәк тә Камал һәм Качалов исемендәге театрларга күпләп йөргәннәр.

«Мәдәният» илкүләм проекты программаларын тормышка ашыруда да Татарстан яхшы күрсәткечләргә ирешкән, планны 100 процентка үтәгән. Ирада Әюпова әйтүенчә, бу елдан яңа юнәлештә эш башланачак. Ул муниципаль дәрәҗәдәге музейларны төзекләндерүгә бәйле. «Республикада әлеге проект нигезендә Лаештагы туган якны өйрәнү музеена капиталь ремонт ясау өчен федераль бюджеттан 20 миллион 788 мең сум акча бүлеп бирелгән», – дип хәбәр итте министр.

Тагын бер күңелле яңалык Фешин исемендәге сәнгать училищесына кагыла. Быел аның базасында «Россиядә уйлап табылган» дигән проект кысасында креатив индустрияләр мәктәбе ачылачак. «Бу – 12–17 яшьлек үсмерләр өчен яңа мәйданчык. Ул аларның иҗади, дизайн юнәлешендәге фикерләү сәләтләрен ачарга булышачак», – диде министр.

Тик яңасы ачыла, искесе төзекләнделә, дип сөйләсәк тә, Татарстандагы дәүләт учреждениеләренең яртысыннан артыгы канәгатьләндерерлек хәлдә түгел. Әйтик, авыл мәдәният йортларының – 27, музейларның – 23,5, балалар сәнгать мәктәпләренең 23 процентына ремонт кирәк.

Ирада Әюпова утырышта депутат Туфан Миңнуллинның Дәүләт Советындагы соңгы чыгышын телгә алды. Ул чакта мәрхүм шәхесебез өч мәсьәләгә – Милли китапханә, Түбән Кама драма театры һәм Чаллы драма театры биналарының торышына тукталган иде.

– Горурланып әйтә алам: бу сорауларга бүгеннән нокта куелды, – диде министр һәм Чаллының «Мастеровые» театры бинасын төзекләндерүдән соң быел ачылалары турында әйтте.

Бинасы гына түгел, эчтәлеген булдыручы да кирәк. Бу җәһәттән эш бирүче белән югары уку йорты арасындагы элемтәне ныгыту, кадрлар әзерләү юнәлешендәге эшне үзгәртү зарур. Ирада Әюпова әйтүенчә, мәдәният-сәнгать учреждениеләрендә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 39193 сумны тәшкил итә. 2021 елның декабрендә узган Дәүләт Советы комитеты утырышында башка сан яңгыраган иде. Мәдәнияткә хезмәт итүчеләр 37,8 мең сум акчага эшли иде ул чакта.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Хәрбиләргә дә артачак

Быел гадәти пенсионерларның гына түгел, хәрбиләрнең, хокук саклау хезмәткәрләренең пенсиясен дә 8,6 процентка арттырырга кирәк. Россия Президенты Владимир Путин шулай дип белдергән. Бу хакта Кремльнең матбугат хезмәте хәбәр итә. Дәүләт башлыгы Эчке эшләр министрлыгы, «Росгвардия», МЧС, Генераль прокуратура, Тикшерү комитеты һәм башка көч структурасы хезмәткәрләре пенсиясен инфляциядән зуррак дәрәҗәдә индексацияләү зарурилыгын әйткән. Илдә мондый пенсионерлар саны – 2 миллион 600 мең чамасы. Президент искә төшереп үткәнчә, моңа кадәр хәрбиләрнең пенсиясен октябрь аеннан 4 процентка арттыру күздә тотылган булган. Әмма, аның фикеренчә, беренчедән, аңа кадәр озак, икенчедән, бу барыбер инфляциядән түбән күрсәткеч булачак. Владимир Путин Хөкүмәткә, әлеге мәсьәләне якын араларда ук хәл итеп, хәрбиләргә февраль ае пенсиясенә гыйнвар ае өчен өстәп түләргә кирәклеген әйткән.

Эшләгәнгә эш булачак

Татарстанда мәҗбүри эшкә хөкем ителгәннәр өчен 400 яңа эш урыны булдырылачак. Шулай итеп, алар өчен эш урыннары 850гә җитәчәк. Бу хакта Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе контроль бүлеге башлыгы Айрат Хәбибуллин белдерде. Аның әйтүенчә, узган елда Казанның 1нче Төзәтү үзәгендә 60 урын булдырылган. Түбән Камада ИК-4 карамагындагы Төзәтү үзәгендә ремонттан соң өстәмә 50 урын барлыкка килгән. «Нинди дә булса предприятие безгә тулай торактан урыннар бирсә, бу предприятиене билгеле бер осталыкка ия булган эшчеләр белән тәэмин итәчәкбез. Без әлеге юнәлештә хезмәттәшлеккә әзер», – дигән Хәбибуллин.

Гаеп – атта да, тәртәдә дә

Узган елда Россельхознадзор идарәсенә кырларга химикатлар сиптергәннән соң бал кортлары үлү турында уннан артыграк шикаять кергән. Бу хакта идарә башлыгы Илнур Галиев белдерде.

Мөрәҗәгатьләр алыну сәбәпле, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә тикшерүләр үткәрелгән. Алты очракта пестицидлар куллану кагыйдәләрен бозу ачыкланган. Гаепле кешеләр административ җаваплылыкка тартылган. Ләкин идарә башлыгы фикеренчә, бал кортлары үлүгә кайвакыт умартачылар үзләре дә гаепле. Ник дигәндә, алар кырларга химикатлар сиптереләчәге турындагы хәбәрләргә игътибар итми. Әйтик, Мөслим, Арча, Мамадыш, Кама Тамагы районнарында шундый очраклар булган. Шуңа күрә Илнур Галиев ике якка да аралашып торырга, законны үтәргә киңәш итте.

Көн кадагында

Тынычланырга иртәрәк!

Коронавируска бәйле вазгыятькә багышланган матбугат очрашуында Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина шулай дип белдерде. Соңгы бер тәүлек эчендә генә дә республикада коронавирус йоктыруның 114 яңа очрагы ачыкланган. Пандемия башланганнан бирле Татарстанда ковид белән авыруның 44859 очрагы теркәлгән.

Бер атна эчендә республикада яңа вирустан саклану кагыйдәләрен үтәмәгән оешмалар саны да арткан. «Тынычланырга иртәрәк. «Омикрон», алдагы штаммнар белән чагыштырганда, 5–7 тапкыр йогышлырак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шуңа күрә эштә бер кеше авырып китсә, чир бөтен коллективны аяктан егарга мөмкин», – диде белгеч үз чыгышында.

Яңа штамм димәктән, бүген Татарстанда соңгы арада телдән төшмәгән «Омикрон»ның 11 очрагы теркәлгән. Якын арада бу сан артып китмәгәе. Ник дигәндә, республиканың Роспотребнадзор идарәсе белгечләре Саратовтагы «Микроб» фәнни-тикшерену институтына 173 яңа проба юллаган. Шушы көннәрдә нәтиҗәсе әзер булыр дип көтәләр. «Омикрон» штаммының асылы турындагы бар мәгълүмат әлегә фаразлар дәрәҗәсендә генә. «Элегрәк коронавирус йоктырган кеше ис, тәм сизми башлый иде. «Омикрон» эләккәндә исә бу билгеләр күзәтелмәскә дә мөмкин», – дип ачыклык кертте Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков.

Иртәгә Республика клиник хастаханәсендә кабат ковид госпитале эшли башлаячак. Хәтерләсәгез, декабрь ахырында ул төзекләндерүгә ябылган иде. «Табиблар соңгы ике елда гадәткә әверелгән шул ук режимда эшләвен дәвам иттерәчәк. Коронавируска бәйле вазгыять катлауланган очракта Республика балалар клиник хастаханәсендәге ятак урыннар саны да ике тапкыр артырга мөмкин», – дип белдерде Владимир Жаворонков.

Сүз уңаеннан, якын арада коронавируска каршы вакцинаны балаларга да ясый башлаячаклар. Сүз 12–17 яшьлек үсмерләр турында бара. Гыйнвар ахырына кадәр Татарстанга балалар өчен чыгарылган вакцинаның беренче партиясе кайтачак. Өлкәннәргә кадый торган «Спутник» вакцинасы нигезендә ясалган әлеге прививканы башта борынга салачаклар дигән хәбәр таралган иде. Әмма белгечләр бу мәгълүматны кире какты. Балаларга прививканы беләккә ясаячаклар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Камил СӘМИГУЛЛИН, Татарстан мөселманнарының Дини нәзарәте җитәкчесе, мөфти:

Милләтара мәсьәләләр теләсә кайсы кешенең күңеленә якын. Ул һәр көнне игътибар таләп итә. Бу өлкәдә дилбегәне йомшартырга һәм аны үзагымга куярга ярамый, гәрчә ул җирлектә динара мөнәсәбәтләр җайга салынган булса да. Татулыкны саклау юнәлешендә даими эшләргә һәм аңлашылмаучанлыкларга юл куймаска кирәк. Теләсә нинди ялган хәбәр (ә алар бүген бик күп) халыклар арасындагы татулыкны юкка чыгарырга мөмкин.

(«Татар-информ»га биргән әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ МАВЫГУЛАРЫ

Китап, газета уку, спорт һәм бакча. Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләрнең буш вакытта ни белән шөгыльләнүләре турында белешкән. Шунысы ачыкланган: сораштыруда катнашучыларның 45 проценты үз мавыгуларына күбрәк вакыт бүлеп бирергә тели икән.

Даими шөгыле юк	27%	Балык тоту	8%
Китап, газета уку	12%	Аучылык	8%
Спорт	9%	Бәйләү	8%
Бакчачылык	9%	Рәсем ясау	6%

Юлыңа поши чыкмасын

Узган ел Татарстанда кыргый хайваннар юлларда 150 авария очрагын китереп чыгарган. Бигрәк тә пошилар, кыр кәҗәләре һәм кабан дуңгызлары машина йөртүчеләрнең юлына аркылы төшә. Башлыча мондый хәтәр хәлләр караңгы төшкәч яки төнлә була икән.

Татарстанның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәгълүматларына караганда, узган елда 167 кыргый хайван, юлга чыгып, машина астына эләккән. Шуның 45е – кабан дуңгызы, 95е – поши, 25е – кыргый кәҗә һәм 2се – затлы болан. Мондый аянычлы хәлләр Питрәч, Алабуга, Азнакай һәм Әлмәт районнарында бигрәк тә еш күзәтелә. Дәүләт комитеты хезмәткәрләре әйтүенчә, машина йөртүчеләргә урман-тыюлыклар тирәсеннән узганда игътибарлы һәм сак булырга, кыргый хайваннар килеп чыгу ихтималы турында кисәткән юл билгеләрен күз уңыннан ычкындырмаска кирәк.

peakpx.com

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Гыйлем һәм капитал

СССР заманнары сагындыра кайчак. Яшьлек тә шул чорга туры килгәч, сагынмый хәл юктыр инде ул. Ул заман дигәндә, язмаларда да, уйларда да аны гел икегә бүлеп карарга гадәтләнелгән: 50 нче еллар урталарына кадәр дәвам иткән, әти-әниләр, әби-бабайларга кыен ашаткан караңгы һәм рәхимсез елларга һәм безне үстергән, бушка укыткан, эшле, тораклы иткән аннан соңгы кеше йөзле һәм «вегетариан» дәвергә.

Икенче дәвернең, аңа караган 30–35 елның уңай яклары тагын шунда иде: хакимият ул чорда илдә укымышлылык культы тудыра алды. Советлар Союзы халкы дөньяда иң күп китап укучы һәм иң гыйлемле халыкларның берсе булып куйды. Килешегез, олы, чал тарихта сирәк күренеш. Слесарь булып эшләгән күршемнең китаплардан сыгылып торган киштәләрен, ул гына җитмәгән, атна саен китапханәгә йөрүен, өенә дистә ярымлап газета-журнал алдыруын яхшы хәтерлим. Нәкъ шул чорда илдә бөтен дөньяга үрнәк белем бирү системасы да булдырылган иде. Ләкин…

Язмыш көлүе, аның бер ирониясеме, китап культы, мәгърифәтнең чәчәк атуы совет чорының азагын да якынлаштырды. Дөресрәге, ул як та үз ролен уйнады. Гыйлемле халык коммунизм тантанасына ышанудан туктады. Туктамаганда да, аңа шикләнебрәк карый башлады. Советлар Союзы бәйсез дәүләтләргә бүлгәләнгәндә, шул ук Беловежье килешүенә кул куелган көннәрдә, ул стройны, ул идеологияне яклап, беркем дә урамга чыкмады, каршылык күрсәтмәде. Бәлки чыгарга кирәк булгандыр. Бүгенге наданлык эпидемиясе булмасын, килмәсен өчен генә булса да.

Укымышлы, затлы җәмгыять дип хыялланган коммунистлардан аермалы буларак, капиталистлар, бигрәк тә аларның бездәгеләре, бәндәдәге гыйлемне бер дә хупламый бүген. Алар – романтиканы белмәгән каты прагматиклар. Алар фикеренчә, бәндә надан, бераз томанарак та икән, ул зыянсыз гына түгел, файдалы да. Әлбәттә, сүз ниндидер техник, технологик томаналык хакында түгел, ә иҗтимагый фикер, сәяси карашлар булмау, җәмгыятьтәге процессларны аңларга, анализларга тырышмау турында. Мантыйк гади: гавам гыйлемсезрәк булган саен, аны ныграк файдаланырга, аны кулланып, күбрәк акча эшләргә, гомумән, андый гавам белән проблемасыз идарә итәргә мөмкин. Аекның уендагы – исерекнең телендә, дигән кебек, эре капитал кесәсен һичкайчан буш тотмаган Жириновский бу тезисны Дума трибунасыннан да даими искәртеп тора. «Яшь буын артык гыйлемле булырга тиеш түгел, андыйлар – власть өчен бәла», – ди ул.

Гыйлемлелек кенә түгел, аның белән янәшә йөргән мәдәниятлелек тә шәп нәрсә түгел капитализм күзлегеннән караганда. Мәдәниятле кешенең әллә иң яңа модалы айфонга һушы китәме? Юк. Куллану җәмгыяте өчен, капиталист кесәсе өчен файдалы түгел мәдәниятле зат. Ул машинасын алыштырырга да атлыгып тормый. Галимҗан Ибраһимовка яисә Толстойга мөкиббән кешедән, кичләрен телевизор карыйсы урында Моцартны, Чайковскийны тыңлаучылардан капиталистик икътисадка нинди яхшылык инде ул?! Андыйлар артканда, керем кими. Ул гынамы? Канәгатьсезлек күрсәтеп шыңшучылар, «көфер» фикер тудыручы, аны таратучылар да шул гыйлем һәм мәдәният ияләре ич инде.

Керем дип шашынучылар бәндәне куллану җәмгыяте кысасында, шул җәмгыятьтәге язылган һәм язылмаган кануннарга буйсынулы хәлдә тоту ягында. Ә моның өчен халыкны без әйткән иҗтимагый-сәяси фикердән, уйланулардан аралау фарыз. Бер уйлаганда, бу артык авыр да түгел. Күпне күрү, белү, уйлану адәми затның холкына болай да бик үк туры килеп бетми. Башны катырмый яшәү җиңелрәк: «азрак беләсең – тынычрак йоклыйсың». Уйга җим, фикер төрлелегенә сәбәп булмасын, дигәндә мәгълүмат кырында трафаретлар эшләргә тиеш. Төрле «авторитет»лар тудырган гомуми карашлар өстенлек итәргә. Ул чагында кешенең үз, шәхси фикере тумый, аңа урын калмый. Телевизордан алып баручы, артист, аерым сәясәтчеләрне тыңлагач, үз «шарик»ларыңны әйләндереп тормасаң да була. Сәясәттән читтә торсаң, бигрәк тә яхшы.

Уртакул обыватель эштән кайтып, тамагын туйдыргач, бүген нишли? Телевизорын кабыза һәм күңел ачтыра торган тапшырулар эзләргә тотына. «Ихахай-михахай»лы тапшыру карауны ул чын ял дип кабул итә. Кирәгеннән артык карун капиталистка бу – бал өстенә май. Бу – бәндәне күңел ачтырып миңгерәүләтү. Әгәр бәндә «Комеди клаб» урынына сәяси тапшыру, сәяси дебатлар (алар «яшник»тә булган тәкъдирдә) карап юана башласа, аңарда нейрон бәйләнешләре эшләп китәчәк, ул уйлый башлаячак. Уй-фикерле зат – хәтәр зат. Ул син төзегән система, икътисади мөнәсәбәтләр, режим белән килешмәскә, аңа каршы чыгарга, синең табышыңа, ашыңа таракан булып төшәргә мөмкин. Каналлар саны йөздән артып киткән телевидение бүген үз вазыйфасын төгәл үтәп килә, хуҗаларга файдага эшли. Дозировканы белмәгән күңел ачу интеллектны күгәртә тора, баш миен селкетмичә яшәргә өйрәтә…

Гавамдагы яшәү мәгънәсе куллану, сатып алу, күңел ачу аша яшәештән допинг алып торуда икән – капиталист тыныч. Кәмит, тамаша-шоу карап, үзеңне канәгатьләндер, кирәкме ул, кирәкмиме, таныш-белешләреңдә булганны ал да шуңа куан, рәхәтлек кичер. Танышларыңны уздырасың икән, син, гомумән, супермен. Һәм шулай яшәү – иң дөресе. Бу – бүген үзеңне үзең алдында күтәрү, үзеңнән канәгать булу формуласы. Русча ул самоутверждение дип атала. Бер җырчы хакында «концерты дәвамында сигез күлмәк алыштырды» дип яздылар. Бу урында үтә кискен эпитетлар китерәсе килсә дә, китермим. Бу – үзең зәвыксыз булудан бигрәк, зәвыксызлыкны пропагандалау. Һәм инде очсызлы самоутверждение. Ә менә җырчының сәхнәгә кием алыштырырга түгел, җырлар өчен чыкканын белгән Эльмира Кәлимуллина мин телевизордан караган сольный концертында бердәнбер, ләкин талантын, зәвыклылыгын ассызыклап торган затлы күлмәген киеп җырлады. Бар да өметсез түгел, димәк. Ул концертны тамаша дип атарга да тел әйләнми. Җыр сәнгатенең нинди булырга тиешлеген күрсәтү булды ул…

Гыйлемлелек, мәдәниятлелек, зәвыклылык культы яши-яши барыбер яралыр, өстенлеккә ирешер дип фаразлыйк. Җиһанны коммунизмнан арындыруда өлеше булган ул фактор капитализмны да кайчан да булса табутка салмагае. Табышка, кеше өлешенә керүгә корылган, бәндәне кулланучы, уй-фикерсез мал җыючы иткән ул система камиллектән ерак формация чөнки.

ҖИДЕ КАТ ҮЛЧӘП, БЕР КАТ ТӨЗИСЕ

Халыкка уңайсызлык тудырмас өчен, Казан тирәсендәге торак йортлар юл һәм социаль инфраструктура үсешен исәпкә алып төзелергә тиеш. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә әйтте. Россиянең Хисап палатасы Рәисе Алексей Кудрин катнашында узган җыелышта Татарстан агломерацияләренең социаль-икътисади үсеш проблемалары турында фикер алыштылар

Президент утырышта билгеләп үткәнчә, зур шәһәрләр агломерацияләре төбәк икътисадының үсеш нокталары булып тора. Әмма аларны үстерү өчен заманча хокукый база һәм акча кирәк. «2030 елга Татарстанның социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләгәндә үк агломерацияләрне үстерү икътисадның төп үсеш нокталары сыйфатында күздә тотылды. Бүген бу хакта күп сөйләнелә, Федераль Хөкүмәт тә әлеге теманы әледән-әле кузгатып килә. Әмма төбәкләр бу мәсьәләдә күп кенә кыенлыкларга дучар. Беренче чиратта – агломерацияләрне үстерүнең хокукый базасын булдыруда һәм финанс белән тәэмин итүдә кыенлыклар бар», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Стратегия – 2030 документында өч – Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләрен үстерү каралган. Татарстан Президенты билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта аларны үстерүгә инфраструктура булдыру өчен кредитлар бирү ярдәм итә. «Казан агломерациясенең Лаеш һәм Яшел Үзән өлешен үстерә башладык. Чираттагы этап – Кама агломерациясе, Тукай районы», – дип ачыклык кертеп үтте ул.

Президент шулай ук республикада агломерацияләрне үстерү өчен яңа автомобиль юллары кирәклеген искәртте. Кама кластерын үстерү максатында, Кама елгасы аша күпер салып, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен читләтеп юл төзү кирәк. Нефть төбәгендә өченче агломерацияне үстерү Алексеевск – Әлмәт автомобиль юлын (Баулыга кадәр илтә) төзүгә бәйле. «Өч агломерация буенча да җитди эш алып барыла», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент, Татарстанның социаль-икътисади үсешенә кагылып, фатир бәяләре артуга һәм ипотека кредитлары кыйммәтләнүгә карамастан, 2022 елда кимендә 3 миллион кв. метр торак төзү нияте барлыгын әйтте. Әмма торак белән генә булмый. 2021 елда социаль инфраструктура һәм уңайлы мохит булдыруга 100 млрд сумга якын акча тотылган, алар хисабына 7 мәктәп, 17 балалар бакчасы, 74 сәламәтлек саклау объекты, 30 спорт объекты, 15 мәдәният объекты төзелде, 70 иҗтимагый киңлек һәм 1 меңнән артык ишегалды территориясе төзекләндерелде.

Рөстәм Миңнеханов төзелеш алып барганда барысын да исәпкә алырга кирәклеген тагын бер кат кабатлады. Юллар да, халык өчен шартлар да булырга тиеш. «Без боларны бераз кулдан ычкындырдык һәм безнең шәһәр яны бик тиз үсте. Бизнес ул төзи, сата һәм шуның белән вәссәлам. Ул урынга кем хезмәт күрсәтәчәк, социаль инфраструктура кайда булачак?» – дип сорау куйды Президент. Аның сүзләренә караганда, шәһәр яны үсешен планлаштыру белән яңа структура – Татарстан Республикасы Пространство үсеше институты шөгыльләнәчәк. Аны булдыру турында карар инде кабул ителгән. «Килешәм, бу мәсьәләдә соңга калдык. Бу вакыт эчендә бик күп хаталар ясалды. Хаталар тагын да булачак әле. Бездә Югары Ослан, Яшел Үзән, Питрәч, Лаеш районнарында 30 мең гектарга якын мәйдан торак төзү өчен кучерелгән. Җир белән проблемалар юк, әмма институт билгеләгән нормаларны һәм стандартларны исәпкә алып төзергә кирәк», – диде ул.

Ачкан җирдә уйнарга кирәк

Казанны Россиянең спорт башкаласы дип атауларына ияләндек инде. Бу исемгә тап төшермәс өчен, республикада шактый көч куела. Татарстанда 2022 ел Цифрлаштыру елы буларак игълан ителгәч, спорт өлкәсендә кабат үзгәрешләр чоры башланды. 2021 елдан республиканың барлык спорт мәктәпләре дә «Мой спорт» мәгълүмат системасына күчә башлады. Тренерлар да, спортчылар да үз күрсәткечләрен шунда теркәячәк.

zenit-kazan.com

Татарстан Спорт министрлыгының коллегия утырышында узган елга нәтиҗә ясап, алга таба ни буласы турында сөйләштеләр. Россиянең спорт министры Олег Матыцин сүзләренчә, соңгы елларда да Татарстан халыкара дәрәҗәдәге спорт чаралары уздыру буенча дөнья аренасында үз исемен аклый килә.

– Безнең үткәнебез генә түгел, спортлы киләчәгебез дә бик матур булачак. Татарстанга ышанычым зур, чөнки Рөстәм Миңнеханов кебек тренер белән начар уйнап булмый. Нәтиҗәләр ясаган вакытта да спорт өлкәсенең барлык тармакларына игътибар бирүегез күренә. Иң мөһиме – халыкны тыңлап, аны ишетеп эш итәсез. Хәзер исә, йомшак якларны исәпкә алып, шушы югарылыкны сакларга кирәк, – диде ул чыгышында. – Җыелма команда вәкилләрен төбәкләп бүлеп карарга яратмасам да, Татарстанның өлеше турында әйтми мөмкин түгел. Җәйге Олимпия Уеннарында биш спортчы һәм бер алтын медаль – төбәк өчен зур күрсәткеч. Пекинда узачак Кышкы Олимпия Уеннарыннан да спортчыларыбыз медальләр белән кайтыр дип ышанам.

Тармакның еллык коллегиясе утырышы, яхшы күрсәткечләр турында сөйләп, уңышлар белән мактанып кына узмады, билгеле. Бүген Татарстанда 11,5 меңнән артык спорт объекты эшли. Шуларның 311е 2021 елда ачылды. Барлык шәһәр һәм районнарда олысына да, кечесенә дә спорт белән шөгыльләнү өчен барлык мөмкинлекләр каралган. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шушы мөмкинлекләрдән файдаланучыларның санын арттыруны бурыч итеп куйды.

– Бездәге кебек спорт корылмалары башка бер җирдә дә юк. Сан буенча да, сыйфат ягыннан да. Бу яктан бик бәхетле без. 2022 елда шушы спорт корылмаларын тотыруны төп бурычларыбызның берсе итеп куярга кирәк. Төзеп, тантаналы төстә ачып кына эш бетми. Без халык өчен эшлибез – шуны онытмаска кирәк. Спорт өлкәсе турында сөйләшкәндә, Татарстан халкының бер өлеше генә түгел, күбесе спортка тартыла, диярлек булсын, – диде ул.

Спорт министры Владимир Леонов тармакның тагын бер проблемалы мәсьәләсенә тукталды.

– Тренерларның эштән китүе борчый. Әйтик, соңгы өч ел эчендә 1600 тренер башка эшкә күчкән. Шуңа бәйле рәвештә, республикада берничә ел дәвамында уңышлы башкарылучы «Земский доктор» һәм «Земский учитель» программаларына охшаган, яшьләрнең торак шартларын яхшыртуга юнәлтелгән «Земский тренер» программасын булдырырга тәкъдим итәбез, – диде спорт министры.

Әлегә Татарстанда яшь тренерларга эшкә урнашканда бер мәртәбә бирелә торган 20 мең сум (2021 елда бу акчаны нибары 10 яшь белгеч алган) һәм айлык өстәмә 1111 сум акча түләнә. Леонов әлеге суммаларны арттыру өчен дәүләт ярдәме кирәк булуын искәртте.

Әни әйткәнчә булачак

Татарстан 12–17 яшьлек балалар өчен «Спутник М» вакцинасы кайтканны көткәндә, мәктәпләрдә әти-әниләрдән рөхсәт кәгазе җыя башладылар. Алар прививкага нинди мөнәсәбәттә? «ВТ» хәбәрчесе мәктәпләрдәге вазгыятьне белеште.

Әлегә республикага вакцина кайтмаган. «Ай ахырына кадәр кайтыр дип көтәбез. Ул мәҗбүри түгел, ирекле булачак», – диделәр бу атнада узган матбугат очрашуында. Ихтыяри дигән сүз әти-әниләрне тынычландырмый, билгеле. Алар арасында бик сирәкләре генә балаларына вакцинация ясатырга риза.

Казан мәктәбендә эшләүче табиб Әлфия Нуриева әйтүенчә, кышкы каникулга чыкканда, укучыларның кулына рөхсәт кәгазе биреп җибәргәннәр. Әти-әниләре прививка кадатуга риза булу-булмавын әйтергә тиеш. Әлегә бу мәктәптә 190 укучының 12се генә ризалык белдергән.

– Һәр яңа әйбер куркыта. Башта үзем дә ярты ел кадатмыйча йөрдем. Ирем ясаткач, мине дә үгетли башлады. Барысы да җиңел генә узды. Бик кечкенә дозада бу. 0,5 миллилитр сыеклыкны 50–60 кило авырлыктагы гәүдәгә кертүдән әллә нәрсә булмый. Прививка балалар өчен эшләнгән. Хәзер тугач ук 14-15 төрле вакцинация үтәләр. Тагын берсе генә организмны какшатыр дип уйламыйм. Бигрәк тә үсмерләргә үткәрергә кирәк. Уку җиңел түгел, имтиханнар буенча да стресс туа?! Берәр нәрсә булса, хәлсезләнәләр. Аларны сакларга кирәк. Интернетта прививка турында нинди генә начар сүзләр язмыйлар. Имеш, үсмерләргә зыян салырга җыеналар. Нинди тузга язмаган фикер инде бу. Балаларны аз тапкач, киресенчә, алар сәламәт булсын дип тырышабыз, – ди Әлфия Нуриева. – Мәҗбүри булмагач, әти-әниләрнең ясатасы килмәячәк. Олылар да, эшкә чыга алмыйсың, дигәч кенә ризалаштылар. Балаларны укытмыйча булмый бит инде. Хәзерге вакытта укытучылар арасында да аңлату эшләре алып барабыз. Вакцина ясатканнар – 5, ә ясатмаганнар 20 көн авырып, әле дә рәтләнә алмый. Озак авыргач, бөтен организм эштән чыга. Бернәрсәдән курыкмыйча, ясатырга кирәк.

Мамадыш районының мәгариф идарәсе җитәкчесе Илдус Габдрахманов белдергәнчә, аларда әлегә прививка хакында әти-әниләр белән сөйләшүләр булмаган. «Бүген беренче тапкыр шәһәр мәктәпләре директорларын җыеп, табибларны, белгечләрне чакыртып, җыелыш уздырдык. Шуңа күрә әти-әниләрнең фикерен бер атнадан гына әйтә алабыз. Без гаиләдә прививка кадаттык. Улыбызга – 15 яшь. Ул да: «Сез ясаткач, мин дә каршы түгел», – диде. Улым, бу – сәламәтлек, дип аңлаттым», – ди Илдус Габдрахманов.

Казандагы 2 нче гимназия директоры Рамил Гайнуллинның да фикерен белештек.

– Бездә укытучыларның барысы да вакцина салдырды. Бу яктан тыныч. Балаларга килгәндә, кистереп кенә әйтә алмыйм. Яшь организм бит. Сәламәтлек турында уйланырга кирәк, әлбәттә. Ирекле булса, әйбәт булыр иде. Моны тулысынча әти-әниләргә тапшырырга кирәк дип уйлыйм. Аларның фикерен белү өчен, җыелыш уздырырга кирәк булыр, – диде Рамил Гайнуллин.

Башкалабыздагы 187 нче лицей директоры Гөлнара Галиева әйтүенчә, уку йортында балаларның сәламәтлеге буенча көн саен күзәтү алып барыла. Хәзерге вакытта укучыларның 5–6 проценты салкын тиеп авырый. Аларга ОРВИ дип куелган, ковид белән авыручылар юк. Әти-әниләрдән вакцина ясатуга карата ризасызлык белдерүчеләр булмаган.

– Медальнең ике ягы бар, диләр бит әле. Бер яктан, прививканың авыруны, дәресләр өзелмәүне туктаучы юл икәнлеген аңлыйбыз. Икенче яктан, әти-әниләрдә вакцинаның ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуы, тикшерелгәнлеге мәсьәләсендә шик бар. Бездә дә барлык мәктәпләрдәге кебек сыйныф җитәкчеләре әти-әниләрдән ризалык җыя. Шуңа күрә күпмесенең каршы яки риза икәнлеген әйтә алмыйбыз, – ди Гөлнара Галиева.

Саба районының Теньки авылында яшәүче җиде бала әнисе Илдария Гомәрова ул-кызларына прививка кадатырга каршы түгел. «Куркырга кирәкми, балаларның киләчәге, сәламәтлеге турында уйларга кирәк», – ди ул, яхшыга өметләнеп.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эпидемиологы Дмитрий Лопушев республиканың 200 мең доза вакцинага заявка бирүен әйтте. Әмма беренче партиядә күпме кайтачагы билгеле түгел. Аны сырхауханәләрдә, мәктәпләрдә һәм урта һөнәри уку йортларындагы медицина кабинетларында ясатып булачак.

Сәрия МИФТАХОВА

«Спутник М» вакцинасы өлкәннәргә кадый торган «Спутник» вакцинасы нигезендә ясалган. Ул ике компоненттан тора. Алар 21 көн аерма белән ясала. Коронавируска каршы вакцинаны балаларга да ясый башлыйлар.

СЫЕР БИРМӘК – ҖАН БИРМӘК

Ветеринарларга: «Бүген бездә бер авыру да юк», – дип тынычланырга ярамый. Аларга терлекләр арасында йогышлы авыруларны булдырмый калу өчен һәрвакыт уяу булырга туры килә. Бездә булмаса, күрше-тирәдә әледән-әле йогышлы авырулар калкып чыга. Узган ел Татарстан белгечләренә дә кош гриппы, дуңгызларда Африка чумасы, котыру авыруы белән көрәшергә туры килде.

Инде бу атнада күңелсез хәбәр килеп ирешге: Сарман районындагы шәхси хуҗалыклардагы мөгезле эре терлекләрдә төенле дерматит (нодуляр дерматит) авыруы ачыкланды. Әлеге тиз тарала торган куркыныч авыру Оренбург өлкәсеннән сатып алынган бозаулардан кергән булырга тиеш, дип фаразлана. Бер хуҗалыкта – 9, икенчесендә 14 баш терлекне юкка чыгарганнар. Районда Татарстан Президенты указы белән карантин игълан ителде.

Еллык коллегия утырышыннан соң Татарстан Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов әлеге хәлгә карата үз фикерен белдерде:

– Әйе, кызганыч, бездә әлеге проблема бар. Аны вакцина ясау юлы белән хәл итәрбез дип өметләнәбез. Куркыныч янаган урыннарда мал-туарга прививкалар кададылар. Бу – безнең территориядә бер тапкыр да күзәтелмәгән яңа авыру түгел. Ике ел булган иде инде. Шуңа күрә аннан бары тик вакцина ясау юлы белән генә котыла алабыз, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Республиканың баш ветеринары тагын бер тапкыр чит төбәкләрдән терлек сатып алучыларга игътибарлы булырга кирәклеген әйтте.

– Малларны «чиста» төбәкләрдән безнең рөхсәт белән генә алып кайтырга кирәк. Ләкин алай гына да килеп чыкмый. Шуңа күрә халык терлек сатучыларның документлары белән кызыксынсын, – диде ул.

Ветеринарларга йогышлы куркыныч авырулар белән беррәттән даими рәвештә очрап тора торганнары белән дә көрәшергә туры килә. Лейкоз – әнә шундый мәкерле һәм еш очрый торган авыруларның берсе. Хәер, республикада ел дәвамында аннан арыну буенча чаралар уздырыла. Нәтиҗәләр дә бар. 2020 ел белән чагыштырганда, лейкоз быел 3,7 процентка кимегән.

– Бездә терлекчелектә сөтчелек юнәлеше алга киткән. Лейкоздан арындыру продукция сыйфаты һәм сөт базарында ихтыяҗ белән бәйле, – диде Алмаз Хисаметдинов. – 2021 елда бу бурыч үтәлде. Бүген йоктыру 5 процент дәрәҗәсендә. 2020 ел белән чагыштырганда, лейкоз 3,7 процентка кимеде. Узган ел республикада 30 хуҗалык лейкоздан арындырылды. Кайбер районнарда эшне дәвам иттерергә, ә кайдадыр тагын да көчәйтергә кирәк.

Баш ветеринар әйтүенчә, терлекләрдә лейкоз авыруы күп булган районнар исемлегенең башында Кама Тамагы килә. Лениногорск, Яңа Чишмә районнарында да хәлләр мактанырлык түгел. Шулай ук Актаныш, Лаеш, Чирмешән, Спас, Кайбыч, Әлки районнарында да проблемалар бар. Ә менә Әтнә, Балтач, Теләче, Алабуга, Кукмара, Саба, Зәй, Арча, Тукай, Сарман районнарында лейкозга каршы эш бик яхшы бара. Аларда ел дәвамында лейкоз юк дәрәҗәсендә.

Республикада терлек санын саклап калу да – мөһим күрсәткечләрнең берсе. Узган ел Татарстанда яңа туган маллар арасында үлем күрсәткече 4,8 процентны тәшкил итә. Ә менә Алексеевск, Чирмешән районнарында бозаулар күп үлгән.

– Үлем сәбәпләре – сулыш алу һәм ашказаны авырулары. Алар турыдан-туры бозауларны тәрбияләүгә һәм туклануга бәйле, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Баш ветеринария идарәсе һәм Россельхознадзор хезмәтенең Татарстан буенча идарәсенең еллык коллегиясе утырышында Россия авыл хуҗалыгы министры урынбасары Максим Увайдов та катнашты. Аның фикеренчә, авыл җирлеге башлыгы ветеринария өлкәсе проблемаларыннан яхшы хәбәрдар булырга тиеш.

– Кош гриппы, башка куркыныч авырулар керә, безгә бу очракта нишләргә кирәклеген аңлау мөһим. Һәр башлык нәрсә эшлисен белергә тиеш. Җирле үзидарә башлыгы оператив мәгълүматлы булырга тиеш. Кемдә

«ВТ» архивыннан

нинди терлек асрала, кем чыгарган, кем керткән, терлеге үлгәч, кая илтә, кем ничек юк итә, кем нинди чаралар күрә? Иң мөһиме – халыкны нинди куркыныч янаганы турында кисәтү кирәк, – диде Максим Увайдов.

Ул хәзерге яшәү рәвешен исәпкә алып, авырулар ягыннан имин төбәккә дә вирус үтеп керү куркынычының зур икәнен әйтте. Белгородта законсыз эшләгән бер предприятиенең куркыныч продукциясе 16 төбәккә, шул исәптән Татарстанга кергән.

– Авыруны вакытында ачыклау мөһим. «Меркурий» системасы продукциянең кая киткәнен билгеләргә мөмкинлек бирә. Куркыныч продукция кибет киштәләренә китмәсен өчен, вакытында ачыклап, әйләнештән алырга кирәк, – дип белдерде Максим Увайдов.

Коллегия утырышында терлекләрне бердәм исәпләү һәм теркәү системасына кертү эшен дәвам иттерергә кирәклеген дә әйттеләр. Татарстанның авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров моңа аеруча басым ясады.

– Быел без авыл хуҗалыгы терлекләрен маркировкалау буенча закон кабул ителүен көтәбез. Шуңа күрә 2022 елда барлык малларны идентификацияләп бетерүне һәм башка төр хайваннарны учетка ала башлауны максат итеп куябыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ БЕЛӘН БЕР ҮК КӨННЕ, БЕР ҮК ЕЛНЫ ТУГАН ДАМИР АБЫЙ:

«ИКЕБЕЗГӘ – 170 ЯШЬ»



Алар икесе бер үк көнне, бер үк елны туган. Берсе – Актаныштa, берсе – Балтачта. Икесе дә бик яшьли җитәкчелек камыты кигән, дәрәҗәләргә ирешкән. Аерма шунда гына: берсе ил, республика күләмендә танылса, икенчесе гомере буе туган районында хезмәт иткән.

Тирән фикерле, мәгълүматлы булуы, шуларның һәммәсен берләштереп, үз фикерен әйтә белүе белән дә, зирәклек ягыннан да икенчесе беренчесеннән һич калышмый. Ул да, нәкъ Беренче Президент кебек үк, пенсиягә чыктым дип өйдә утырмады, район Ветераннар советы рәисе булып, җәмәгать башлангычында эшләсә дә, унике ел буе атнаның биш көнендә район Советы бинасындагы бүлмәсенә гадәти режимда эшкә йөрде. Аның да районда гомер буе абруе зур булды.

– Минтимер Шәрипович үзе белән бер көнне тууыгыз турында беләме иде? – дип сорыйм Дамир абыйдан. – Ни дисәң дә, аның чорында башкарма комитет председателе булып эшләдегез бит.

– Белә иде, – ди ул. – Бер елны туган көненнән соң икенче көнне котларга баргач, мине шелтәләп алды: «Эш урынында утырмыйсың, кичә туган көнең белән котлыйм дип шалтыраткан идем, син юк», – диде. 70 яшем белән котлаганда да: «Икебезгә – 140 яшь», – дип шаяртты (фотода – шул мизгел).

Патефонлы һәм... чабаталы тормыш

Алан авылында заманы өчен хәлле – сыерлы, патефонлы-гармунлы, сәпидле гаиләдә туа ул. Ачлыктан тилмергәнен хәтерләми. Авыл советы секретаре, район финанс бүлегенең налог инспекторы булып эшләгән әтисе сугышта һәлак булганнан соң гына аның өчен чабаталы тормыш башлана.

– Аңа кадәр әби-бабай белән бик тату яшәгән әниемне, әтинең энесе өйләнеп, өйгә тагын бер килен килү белән, берьялгызын ишегалдындагы ак мунчага башка чыгардылар. Мине нишләптер үзләренә алып калдылар, – дип сөйли Дамир абый. – Бераздан әнинең әтисе Насыйбулла бабай ул мунчаны яңа нигезгә күчереп салды. Ә мин, беркемгә әйтмичә, әни янына төшеп киттем. Бу вакытта миңа сигез яшьләр тирәсе булгандыр... Әни бик сөенде инде. Ул атлар карады, мин укыдым. Бөрбашка йөреп укый идем. Сыйныф җитәкчесе булып Аланның Юныс мулла малае Гомәр абый килде. Малмыжда рус-татар мәктәбен тәмамлаган, Сивашны кичкән, армиядән соң Арча педучилищесын, икееллык укытучылар институтын тәмамлаган, Балтач районы мәгарифенә нигез салган, репрессиягә эләгеп, ике ел төрмәдә утырган, сугышта булган, хатынын, улын югалтып, өч бала белән тол калган – кыскасы, бик күпне күргән кеше иде. Ул кече кызы Лена белән Бөрбашка күченеп, иске генә йортта яши башлады. Көннәрдән беркөнне шушы кеше әниемне сорап килде. «Улым риза булса гына», – ди әни. Булачак әти: «Мин үземә хатынлыкка теләсә кемне таба алам, миңа син генә түгел, улың да кирәк», – дип җавап бирә. Ә мин исә аңа бары бер сорау биргәнмен: «Укытырсыңмы?»

Уңай җавап биргән мөгаллим абыйсы башта Дамирны үзләренә кунакка алып китә. Өч көннән соң: «Йә, әниеңне нишләтәбез?» – дип сорый. «Алып кайтабыз», – ди, билгеле, Дамир. Шулай яшәп китәләр.

СССР күләмендәге белгеч

Әти кеше сүзендә тора. Җидееллык мәктәпне грамота белән бетергән Дамир СССР Киң куллану товарлары промышленносте министрлыгына караган (ягъни Союз күләмендәге) Казан мех әйберләр техникумына укырга керә. Техник-экономист белгечлеге алып чыга. Техникум дәрәҗәсендә әзерләнгән беренче белгечләр була алар. Аны Башкортстанның Ишембай шәһәрендәге хәрби киемнәр тегүче фабрикага эшкә җибәрәләр. 885 сум акча, 700 сум подъемный белән (ул чор өчен искиткеч зур саннар була бу). Фабрикада да бу юнәлештә бердәнбер белгеч була ул. Нибары сигез ай эшли. Күрәсең, бик актив егет булган, аннан соң үзен ВЛКСМ шәһәр комитетына учет һәм статистика секторына мөдир итеп алалар. «Миңа ул чакта унтугыз яшь иде. Буем-сыным, гәүдәм булса, бер хәл...»

«Бронь бирәбез, кал», – дисәләр дә, төптән уйларга сәләтле Дамир армиягә барырга карар кыла. Янәсе, бүген калсам да, барыбер барырга туры киләчәк бит... «Күрәчәгемдер инде», – дип өсти ул шул хакта сөйләгәндә. Ул чакта язгы чакырылыш булмаса да, 1956 елның җәендә аны армиягә алалар. 7 июльдә Семипалат атом полигонында сапер булып хезмәт итә башлый. Ә августта атом бомбасын ачык һавада сынау булган.

Икенче җәйдә исә шундый ук сынау җир астында үткәрелә. Монысының да нәрсә икәнен белмиләр, бары 25 ел берни әйтмәскә, берни сөйләмәскә дип кул куйдырганнан соң гына, бу «сер»нең нәрсә булуын чамалыйлар. Әлеге сынаудан соң күп тә үтми, Дамирны хәрби частьның тулы штатлы комсомол секретаре итеп сайлыйлар, бераздан ул ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнә, партиягә керә.

«Я не знайть экономист»

Тик армиядән соң өйдәгеләре чакыруы буенча авылга кайткан Дамирны биредә «признавать» итүче юк. «Әнә урман ташуда эшлә, бәрәңге чыгар», – ди колхоз председателе. Ә райкомда заворг агай: «Я знайть бухгалтер, я знайть нормировщик, но я не знайть экономист», – дип кайтара. Инде ризалашып, колхозда эшли башлаган Дамирның язмышын үзгәртергә бер очраклы хәл җитә. Ул хезмәт иткән частьтагы политотделдан учет карточкасын гына түгел, рекомендация тибындагы бик яхшы характеристика да язып җибәргән булып чыгалар. Әй, йөгерә башлый райондагылар. 24 яшендә инде аны алты авылны берләштергән Фрунзе колхозына партоешма секретаре итеп җибәрәләр. Председатель дә була, район авыл хуҗалыгы идарәсен дә җитәкли, башкарма комитет рәисе, халык контроле, коммуналь милек белән идарә итү комитеты рәисе дә булып эшли. Соңгысыннан вакытында киттем, дип сөенә. Хосусыйлаштыру кебек үтә дә каршылыклы, үтә дә кытыршы процесста өлеше булмауга шөкер итә. Бүгенгәчә күп укый, өйрәнә ул. «Үтә куркынычлы подразделение ветераны» таныклыгын да, күпме киртәләр аша – 45 ел үткәч, ә медален 50 ел үткәч булса да, алуга ирешә. Тагын шундый өч райондашыбызга да ярдәм итә әле.

Гадилеге белән бик күпләрнең хөрмәтен казанган, җитәкче булып эшләгән чорының һәр баскычында кул астындагы күпме сәләтле кешегә үз вакытында үсәргә, «ачылырга» ярдәм иткән, бүгенгә кадәр алар белән кызыксынып яшәгән Дамир абый Габдрахмановның менә шундый бик тә хикмәтле, сокланггыч кеше булуын белдегезме инде? Тормыш иптәше Әлфинур апа өчен 60 еллап ышанычлы, тугры ир дә, балалары өчен төпле, акыллы киңәшче, инде буй җиткән, берсе гаилә корырга өлгергән оныклары өчен дөньядагы иң шәп бабай да ул. Гомер буе кешеләр арасында кайнап яшәгән аксакал – дистә елдан артык инде мәчеткә йөрүче кордашлары, яшьләр арасында да үз кеше. Иң мөһиме, ул үзенең бик тә бәхетле гомер кичерүен, картлыгында да бик бәхетле булуын аңлый. «Бер урыс әйткәндәй, тут болит, тут болит булса да, сиксән биш яшь – гомернең иң матур чагы икән», – дип шаярта...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

СӘВӘЛӘЙ БӨСТӘРЛӘРЕ

Нурлат шәһәрендә үткәрелә торган «Уяв» бәйрәмендә Алексеевлар гаиләсе гел игътибар үзәгендә булды. Олысы-кечесе үзләре теккән милли киемнән, шәхси күргәзмәләрендә чигелгән, тегелгән, бәйләнгән әйберләр күз явын ала. Җырлыйлар, бииләр, сөйлиләр. Чуаш телендә генә түгел, татарчасын да, урысчасын да сиптерәләр генә. Кыскасы, яннарыннан сокланмый үтәрлек түгел.

Бу гаилә Зәй районындагы керәшеннәр яши торган Сәвәләй авылыннан килгән булып чыкты. 36 ел татарлар арасында яшәп, үзләренең телен дә, гореф-гадәтләрен дә оныту башларына да кереп карамаган боларның. Моңа беркем комачауламаган да, эреп юкка да чыкмаганнар. Киресенчә, башкаларга үрнәк булып калганнар. Бигрәк тә шул ягы гаҗәпләндергән дә, сокландырган да иде.

Сәвәләй

Күптән түгел әлеге гаилә белән тагын очрашырга туры килде. Алексеевларның татар авылына килеп урнашуларын язмышка сылтыйк. Бөгелмәдә техникум тәмамлаган Володяны Башкортстандагы Октябрьский районына юллама белән җибәрәләр. Соңрак ул гаиләсе белән Сәвәләй авылына кайтып төпләнә, чөнки монда торыр урын бар: колхозга инженер булып урнашу белән коттедж бирәләр. Елга аръягында Савелий исемле бер чуаш та яшәгән ул чакта. Хәзер инде руслар да, үзбәкләр дә бар икән. Ә ул вакытта яңа туган оныгын карарга әбисе килә дә, Надя татар балалар бакчасында эшли башлый.

– Володя татарча азрак аңлый иде. Мин бер сүз белмәгән килеш эшкә чыктым. Бер дә кыен булмады, бик тиз өйрәндем, – ди ул. Әбиләре янында чуашча өйрәнеп үскән балалары Оля белән Толя да үзеннән калышмый. Мәктәптә дә татарча укыйлар. Шул ук вакытта туган телләренә дә, рус теленә дә хилафлык китермиләр.

– Өй эшләрен әзерләгәндә ярдәм кирәк булса, күршедә генә яшәүче укытучы янына керә идем. Гомумән, Сәвәләйгә килеп, бик уңдык без. Монда халык бик ачык йөзле, ярдәмчел. Православие динендә булгач, аралашып яшәр өчен дә уңайлырак булгандыр инде. Уртак әйберләребез күп бит. Гореф-гадәтләр дә бер үк, бәйрәмнәр дә бергә дигәндәй. Заманында ансамбльгә йөреп, керәшен җырларын да өйрәндем. Авылыбыз гөрләп торды ул вакытта. Хәзер дә 400дән артык хуҗалык бар әле монда. Тик менә яшьләргә эш кенә калмады. Шикәр заводы карамагындагы агрофирмадан терлекне каядыр алып киттеләр дә, анда эшләгән халык Әлмәт, Зәй якларына юл тотты. Мин үзем пенсиядә, Володя нефтьчеләр янында эшләп йөри әле. Колхоз таралгач, арендага җир алып, иген үстереп сату белән шөгыльләнгән иде. Көн-төн эшләгәч, акчасы да табылды.

Нурлат

Район үзәгендә матур гына йорт җиткерүләре – шуның бер дәлиле. Ни өчен Нурлатта, дип сорасагыз, җавабы да бар. Надежда үзе шушы районның Кече Камышлы авылында туып-үскән. Бар туганнары да туган төбәктә яшәп калган. Владимир да – шушы районның Егоркино авылыннан.

– Туган җир барыбер тарта инде, – ди Надежда. – Ирем эшләрен тәмамлаганчы, Зәйдә яшәүче улым гаиләсенә булышырга уйлап торабыз. Киленебез Айсылу оныкларыбыз Аскар белән Артур янына бәләкәч алып кайтырга җыена. Аннан Нурлатка кайтырбыз инде. Анда кызым Ольга белән киявебез Илья гаиләсе яши. Оныкларыбыз Володя һәм Серафима да бик көтә үзебезне.

Сандык тулы байлык

Туган җиргә кайткач та, тагын бер хыялын тормышка ашырырга исәбе бар Надежданың. Кул эшләре остасы ул. Чиккән, теккән, бәйләгән әйберләрен санап та, карап та бетерерлек түгел. Хәер, ул үзе генә түгел, Кече Камышлыдагы Кузьминнар гаиләсендә дүрт ир туган янында үскән кызларның дүртесе дә – һөнәр ияләре. Любовь чигәргә оста булса, Вера белән Ирина тегәргә яраталар икән. Ә менә Надежданың барысына да кулы ята.

– Мин чигү белән кечкенәдән мавыгып киттем, – дип искә ала ул. – Рәсем ясый алмый идем әле. Бик ялына торгач, бизәкләрне абыем Слава төшереп бирде. Беренче тапкырында ул трактор ясады. Аннан бүземә мультфильмнан бүре «кунаклады». Апаларымның яхшы җепләрен әрәм итәсе килми. Начарларын, төссезләрен генә бирәләр. Анысының да җаен таптым. Мәктәптән йөгерә-йөгерә иртәрәк кайтам да сиздермичә генә берәрсенең мулинесен алам. 2 нче сыйныфта беренче сөлгемне чиктем. Кызганыч, анысы юкка чыккан. Әмма бизәген әле дә хәтерлим. Ә менә 3 нче сыйныфтагысы саклана. Сандыктагы байлыкларым арасында әнием эшләгәннәре дә байтак. Үзем бик яратсам да, кызым Оляның бу эшкә кереп китүен бер дә теләмәгән идем. Хәзер чиккән әйберләр белән кешене шаккатыра алмыйсың бит. Кирәге дә юк кебек. Башка эшкә өйрәнсен дидем. Тик ул да нәкъ үзем кебек кача-поса бәйләргә дә, тегәргә дә, чигәргә дә өйрәнде. Рөхсәт итмәгәч, тегү машинасында мин өйдә юк чагында гына теккән. Хәзер оныгыбыз Серафима кул эшләренә ябышты. Авылда да, кул эшләрен тота-тота, ахирәтләрем белән кич утырабыз, бергәләп җырлап та җибәрәбез. Күңелгә рәхәтлек бирә мондый халәт.

Надежда кияүгә чыгар өчен бирнә әзерләгән чакларын да искә алды. Сәвәләйдә хәзер дә бар икән әле ул гадәт. «Яшь килен бөстәрләре» дип атала, ди. Сабантуйга яшь киленнең чигелгән сөлге бүләк итүе дә – табигый хәл. Надежда килене Айсылуга да әзерләргә булышкан. Тик гореф-гадәтләр сакланса да, яшьләр йортка чигелгән әйберләр элүне бик өнәп бетерми икән.

– Шуңа күрә өемне бәйрәмнәрдә генә бизәп куям, – ди Надежда. Шулай да сандык тулы байлыгына туган җирендә лаеклы урын эзләмәкче ул. – Әле ныклап белешкәнем юк. Нурлатка ял көннәрендә генә кайткалап йөрибез бит. Райондагы Халыклар дуслыгы йортында туганым эшли. Ул кайбер эшләремне алган иде. Тик анда музей юк икән. Күченеп килгәч, үз ихатамда берәр музей сыман корылма эшләп куйсаң да ярар иде дип уйлап торам. Борынгы әйберләрем дә күп минем. Килгән-киткән кунакларым, туганнарым, күршеләрем рәхәтләнеп карар иде.

Үз биләмәләрендә музей ясаган кешеләр бар инде ул барын. Әмма мондый байлыкка Нурлатта да битараф калмаслар дип уйлыйм. Гомер буена татарлар арасында яшәп, телен, гореф-гадәтләрен саклап калган, алай гына да түгел, аларны үстерүгә зур өлеш керткән Алексеевлар үзләре дә экспонаттан ким түгел инде. Телгә алып сөйләрлек, үрнәк итеп куярлык.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Дәүләт алдындагы казанышлары һәм күп еллар буе нәтиҗәле иҗтимагый эшчәнлек алып баруы өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, «Татарстан Республикасы Тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне торгызу республика фонды» коммерциясез оешмасының Попечительләр советы Рәисе **Шәймиев** Минтимер Шәрип улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Изге апостол Андрей Первозванный ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Майна** Мария Ивановна, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Сизова** Елена Петровна, хезмәт ветераны **Халиков** Илдус Хәким улы, Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Россия элемтә хезмәткәрләре һөнәр берлеге иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк оешмасы рәисе **Беседина** Раиса Петровна, хезмәт ветераны **Владимиров** Виктор Иванович, «ТСНРУ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Егорушкин** Юрий Анатольевич, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге башлыгы **Закиров** Фәез Фәйзрахман улы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башлыгы **Камаев** Фаил Мисбах улы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы **Кәримов** Разиф Гали улы, «Буаагропромснаб» матди-техник тәэмин итү базасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте каравылчысы **Касыймов** Илдар Нияз улы, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең тарих һәм философия кафедрасы мөдире **Никонова** Светлана Игоревна, Арча муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе урынбасары **Сәгъдиев** Илдус Абдрахман улы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе **Сәгыйрова** Фәнүзә Вәлимөхәммәт кызы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең микро- һәм мезотикшеренүләр бүлеге баш фәнни хезмәткәре **Хәйруллина** Йолдыз Рәкыйб кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен артист, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәхнә ветераннарының «Илһамият» клубы әгъзасы **Шакиров** Җәвит Әхмәтгали улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«КАЗАН ЕГЕТЛӘРЕ» коммерциячел булмаган партнерлыгы директоры, вокалчы артисты (солисты) **Әгъләмов** Айдар Әнәс улына; «Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе оркестры артисты **Кәлимуллина** Фәридә Хаммат кызына; «Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе хорында соло партияләре башкаручы артист **Романцова** Ләйсән Нариман кызына; «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Әхмәдуллин** Ришат Ринат улына; «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Мохтарова** Радуга Илһам кызына; Татарстан Республикасының «Буа дәүләт драма театры» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Солтанов** Илфир Ильяс улына; «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең опера студиясе солисты **Ганиев** Айрат Марат улына, «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең театр, кино һәм телевидение факультеты концертмейстеры **Моратов** Айнур Әлфир улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы «Ак калфак» татар хатын-кызлары төбәк иҗтимагый оешмасының Әгерҗе җирле бүлекчәсе әгъзасы **Акбашева** Лилия Фалих кызына, Азнакай муниципаль районының «Район-шәһәр мәдәният сарае» муниципаль бюджет учреждениесе филиалы – Уразай авылы мәдәният йорты директоры **Әхмәтҗанова** Гөлфия Мөхәммәтша кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Сугыш һәм хезмәт ветераннары халык хоры хормейстеры **Гыйниятова** Гөлназ Зиннур кызына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге башкарма комитетының «Аккирәй авылы мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Квакова** Лидия Дмитриевнага, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы **Кудряшова** Марина Алексеевнага, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Авылара үзәк китапханә» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Липатова** Роза Харис кызына, «Түбән Каманың Салих Сәйдәшев исемендәге музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Привалов** Виктор Евгениевичка, «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең театраль дисциплиналар укытучысы **Хисаметдинова** Эльмира Илдус кызына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авылара китапханәсе муниципаль бюджет учреждениесенең комплектлаштыру бүлеге мөдире **Шәрифуллина** Гөлсинә Галиәхмәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең 7 нче янгын сүндерү-коткару отряды башлыгы урынбасары, эчке хезмәт подполковнигы **Мирзегалләмов** Дилүс Дәүләт улына **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Мамадыш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Красная Горка ветеринария участогы ветеринария табибы **Хәбибуллин** Газизулла Нурулла улына, «Маяк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Хәертдинов** Марат Сәлахетдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Ватаным Татарстан» газетасы коллективы, **Гөлниса Миңлегәрәй кызы АХУНҖАНОВА** вафат булу сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының, таныш-белешләренең авыр кайгысын уртаклаша. Газета «Социалистик Татарстан» исеме белән нәшер ителгән чорда ул 30 елдан артык машинистка (хәреф җыючы) булып эшләде, хезмәтен җиренә җиткереп, зур осталык белән башкарды, башкала мохитендә тәрбия алуга карамастан, татар телен, грамматикасын бик төгәл белә иде.

Хезмәттәшләребезгә булган ярдәмчеллеге, ягымлылыгы белән дә ихтирам казанды. Гаиләсе турында сүз чыкканда тормыш иптәше Рәфгатьне гел «безнең Рәфгать», балаларын «безнең Диләрә», «безнең Айрат», «безнең Азат» дип телгә алды. Коллективта «безнең» сүзе, гомумән, аның үрнәгендә киң кулланышка керде.

Гөлниса Ахунҗановага 75 яшь иде, ул Курган зиратында җирләнде. Авыр туфрагы җиңел булсын!

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Киңәш-табыш

БАЛАМ, СИҢА ӘЙТӘМ!

ӘТИ-ӘНИЛӘРГӘ

✓ Балалар белән сөйләшергә вакыт табыгыз. Аралашу булмаса, арадагы элемтә югала.

✓ Бер-берегезне бүлдермичә тыңларга өйрәнегез.

✓ Балагызга үзегез турында сөйләгез. Бу арадагы мөнәсәбәтләрне ныгытачак.

✓ Өйдәге эшләрне бергәләп башкарырга тырышыгыз. Бергәләп эшләү матур нәтиҗә бирер.

✓ Балага һәрдаим сезнең ярдәмегез кирәк. Шуны онытмагыз.

✓ Баланы теләсә ничек куркытырга кирәкми, ул сезгә ышанудан туктарга мөмкин.

✓ Сүз белән генә түгел, гамәлләрегез белән дә балагызга теләктәш булыгыз.

БАЛАЛАРГА

✓ Әтиең һәм әниең – иң якын кешеләрең. Синнән барысы да йөз чөергән чакта да, алар синең өчен калкан булачак.

✓ Үз эчеңә бикләнмә, әти-әниеңә күңелеңне ач.

✓ Әти-әниеңнән аларның балачагы, үсмер чоры турында сораш. Беренче тәҗрибә туплау нәкъ шуннан башлана.

✓ Әти-әнидән оялырга ярамый!

✓ Юк-бар өчен үпкә саклама.

✓ Еш кына өлкәннәрнең проблемалары күп була. Шуны истә тотып, әти-әниеңә ярдәм итәргә тырыш.

Сорау – җавап

Кызың «тәмлетамак» булса...

Кибеткә керер хәл юк, балабыз һаман зыянлы тәм-том сорый. Һаман да кәнфит, кока-кола, шоколад кына ашатып торып булмый бит. Сәламәтлегенә зыян килер дип куркам. Нишләргә икән?

Гөлүсә Н., 30 яшь

Марина САГИДЕНОВА, балалар психологы:

– Баланы иркәләүнең төрле юллары бар, шул исәптән, тәм-том сатып алып бирү дә. Тик, дөрес әйтәсез, канәгатьләнү хисеннән битәр, бала сәламәтлегенә күбрәк зыян киләчәк.

Мондый хәлдән чыгу юлы бар. Иң элек үзегез үрнәк булыгыз. Ягъни гаиләгез белән зыянлы ризыклардан баш тартыгыз. Тик баш тарту ул әле бөтенләй юк итү дигән сүз түгел. Зыянлы тәм-томнарга алмаш эзләгез. Фаст-фуд урынына бергәләп тәмле дә, файдалы да ризык әзерләгез. Иң җайлы ысулларның берсе – кибеткә йөргәндә баланы үзегез белән алмау, ымсындырмау.

ВЕНЕРА ФАСЫЙХОВА:

«ӨЙДӘ КҮБЕСЕНЧӘ ЭЛЕККЕ ҖЫРЛАР ЯҢГЫРЫЙ»

«Кызым үсә, гөлем үсә», – дип җырлый-җырлый, чәчәктәй кыз үстергән бит Раяз! Өч яшеннән бирле тамашачы күз алдында үскән Венера Фасыйхова турында сүзебез.

:: Венера, сәхнәдәге тәүге чыгышыңны хәтерлисеңме?

– Ул чакта миңа өч кенә яшь иде әле. Әтием белән «Балалы солянка»да «Инде хәзер килмисең» җырын башкардык. Бик ярата идем мин ул җырны, әтиемне дә шуны җырларга күндердем.

Сәхнә белән әле танышкан гына чагымда мин шуны аңладым: матур күлмәкне кигәч, тик кенә утырып торырга кирәк икән *(көлә)*. Ә мин күлмәк итәгенә баса идем дә егыла идем. Кечкенә ич инде! Шуңа да итәгемне әнием гел күтәреп йөрде.

:: Ул чакта үзеңне принцесса кебек хис иткәнсеңдер, әйеме?

– Әлбәттә!

:: Хәзер инде син үзең генә чыгыш ясыйсың, шактый гына проектларда катнашасың. Бу – үз теләгеңме?

– Әйе. «Шаян ТВ» каналындагы «Сәйлән» проектында катнаштым. Дөресен генә әйткәндә, мин анда очраклы рәвештә килеп эләктем. Ләкин әлеге проект миңа күп ишекләр ачты, үз стилемне табарга ярдәм итте.

:: Ә нинди стильдәге җырларны үз итәсең?

– Эстрада, джаз. Джаз стилендә бик җырламасам да, яратып тыңлыйм. Ә эстрада – безнең заманның иң популяр стиле. Андый җырларны тыңларга да, җырларга да яратам. Халыкка да ошый кебек.

:: Сезнең гаиләдә әниегездән кала барысы да җырлый, ахры?

– Әнием дә шундый матур җырлый минем! Мин аны гел сәхнәгә чыгарга үгетлим. Ничек кенә сорасам да, «Юк-юк, кызым, мин сәхнә артында гына торыйм инде», – ди.

:: Ә ул синең кечкенәдән сәхнә юлын сайлавыңны хуплыймы?

– Әйе. Беркайчан да каршы килгәне булмады. Алай гына да түгел, барлык бәйгеләрдә, фестивальләрдә ул минем белән. Дулкынлансам, сүзен табып юата, дәртләндереп тора.

Кунагыбыз турында белешмә

✓ Венера – Люция һәм Раяз Фасыйховлар гаиләсендәге өлкән бала. Аның Рамазан исемле энесе бар;

✓ яшь йолдызчыкка – 13 яшь;

✓ ул Казанның 149 нчы татар лицеенда 6 нчы сыйныфта белем ала;

✓ җырлаудан тыш инглиз телен үзләштерә, кино сәнгатен ярата;

✓ киләчәктә үзен җырчы итеп күрми.

:: Өегездә күбрәк нинди җырлар яңгырый?

– Татар җырлары. Үзебезнең җырларны бик яратам. Аларда ниндидер тылсым бар кебек. Аеруча Эльмира Кәлимуллина, Алинә Шәрипҗанова, Ильвинаның җырларын тыңлыйм. Һәм, әлбәттә, әтием башкаруындагы җырларны яратам. Иң яраткан җырым – «Чулпан».

Гомумән, әтиебез безгә халык җырларын, ретро җырларны тыңларга куша. Болай гына түгел, ә нәкъ менә мәгънәсенә төшенеп, сүзләренә игътибар биреп. Билгеле бер җырларны сайлап, исемлек тә төзеп бирә ул.

:: Киләчәктә кем булырга телисең?

– Мин үземне мода өлкәсендә күрәм. Хәзердән үк шушы өлкәдә «кайнарга» тырышам. Актриса булу теләгем дә бар. Без еш кына татар театрларына йөрибез. Андагы актерларга шулкадәр сокланып кайтам!

:: Ә кино өлкәсендәге актер яисә актрисалардан кемнең иҗатын аеруча яратасың?

– «MARVEL» киностудиясе төшергән фильмнар белән бик кызыксынам. Иң яраткан актрисам – Зендея.

:: Хыялың нинди?

– Яхшы итеп инглиз телен өйрәнеп, Америкага барасым килә. Кем белә бит, бәлки белемне дә шунда алырмын. Актерлык һөнәре дә кызыксындыргач, Голливуд, Лос-Анджелесны үз күзләрем белән күрәсем килә.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Хикәя

ТЕЛЕФОНЛЫ КӘҖӘ

pixabay.com

Госманнарның авылы тау астында урнашкан. Элек авылда телефон тотмый иде. Күптән түгел тау башына зу-ур каланча салып куйдылар. Хәзер әбиләр дә күрше бүлмәдәге бабайлары белән «мобильник» аша гына сөйләшә.

Мәктәптә иң авторитетлы малай кем дип уйлыйсыз? Гел «бишле»гә генә укучымы? Юк. Спортсменмы? Юк. Кемнең телефоны иң кыйбатлысы – шул!

Дөрес, тау башындагы каланчаның зарары турында да күп сөйлиләр. Имеш, ул радиация тарата, имеш, әллә нинди авырулар китереп чыгара икән. Сәрхуш Ибраһимның да үлеме шуның аркасында булган икән, диючеләр дә табылды.

Ерунда! Госман белән Саматның андый уйдырмаларга исләре дә китми. Алар ярыша-ярыша, әти-әниләрен зар елата-елата, яңа «мобильник»лар сатып ала торалар. Алган бере искесеннән шәбрәк, купшырак була бара, телефон гына түгел, үзе фотоаппарат, үзе видеокамера, үзе диктофон, плеер, интернет, тагын әллә ниләр...

Госман белән Самат – күршеләр. Җиденче класста укучы бу ике малайның уртак проблемалары бар. Госманнарның кәҗәсе, Саматларның сарыгы көтүдән кайтмый интектерә. Кичләре шул хәерсезләрне эзләп үтә малайларның. Кайларда гына йөрми ул мөртәтләр: болында, елга буйларында, клуб артындагы кычытканлыкта...

Көннәрдән бер көнне Госманның башына «шап» итеп «гениаль идея» килеп төште. Урраааа! Моннан соң ул кәҗәсен эзләп интекмәячәк. Малай канатланып эшкә кереште. Иң әүвәл үзенең иске телефонына навигатор программасын куйды. Аннары телефонны кәҗәнең муенына асты. Хәзер малкайның кайларда йөрүен интернет аша рәхәтләнеп карарга була иде. Әмма бераз уйланып торгач, телефонны муеннан салдырып алды да, скотч белән бичара кәҗәнең корсагына ябыштырып куйды – тегеләй урлап китүләре бар!

– Нәрсә дивана кәҗәңне акыртасың? – дип шул ук мизгелдә капкада Самат пәйда булды.

– Һе... – дип күкрәген киерде Госман. – Бик беләсең килсә, минем кәҗә акыллы хәзер!

– Нәрсәдә күренә инде аның акылы?

– Мәсәлән... мәсәлән, һәркөнне иртән көтүгә кузгалганда ул миңа кичен кая булачагын әйтеп китә. Моннан соң абзагыз авыл буйлап кәҗә эзләп йөрмәячәк!

Самат дустына сәер итеп карап куйды: «Авырмыймы бу бала?»

– Ышанмыйсыңмы? – дип серле елмайды тегесе. – Менә, кичен миңа ияреп, туп-туры кәҗәбез янына алып барам үзеңне!

Ул көнне Самат ачкан авызын яба алмыйча бик озак басып торды. Чөнки Госман беркая борылмый-нитми туры үзәк урамга атлады һәм «Кояшкай» исемле балалар бакчасы комлыгыннан кәҗәсен ияртеп килеп тә чыкты. Икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды: түбән очтагы ашлама складының ачык ишегеннән кәҗәнең ике мөгезе генә күренеп тора иде...

Өченче көнне Самат дустын кызык итәргә уйлады. Кәҗәне иртәрәк үзе эзләп табып, үз абзарларына бикләп куйды. Биш минут үтте микән, капкада Госман пәйда булды:

– Малай, кәҗә иртән әйтә, бүген кич Саматларга кунакка керәм, ди... – Малай көлеп җибәрүдән көчкә тыелып тора иде. – Чыгар инде сөтлебикәбезне, яме, өйгә кайтырга вакыт аңа...

Аның сүзен җөпләгәндәй, Саматлар абзарыннан сөенечле мәэлдәү ишетелде.

...Әмма иртәгесен кәҗәне табып булмады. Навигатор сүнгән, ике арада элемтә юк иде. Эзләмәгән җир калмады, бөтен авылның астын өскә китереп бетерделәр. И борчылды Госман, и борчылды, соңгы арада тәҗрибә объекты булган кәҗәсе дә, иске телефоны да кызганыч иде аңа.

Инде бичара малкайны бүре ашагандыр дип язмыш белән килешкән мәлләрнең берсендә, уйламаганда-көтмәгәндә, кәҗә үзе кайтып кермәсенме! Хәлсезләнеп, ябыгып, йончып беткән... Госман дүрт аяклы дустын кочаклап алды да телефон булырга тиешле төшне капшарга тотынды. Ләкин малайның кулы «мобильник» урынына ниндидер китапка барып төртелде. Нәни генә бу китапның тышына «Кәрәзле телефонның зыяны» дип язылган иде...

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

Тәмле булсын!

Туңдырма ясау ысулы

Балалар белән бергә аш-су бүлмәсендә кайнашу өчен нишләргә, дисезме? Туңдырма ясарга! Рецепты – бездән.

Йогыртлы туңдырма

150 г җиләк (туңдырылган да ярый);

200 г куертылган сөт;

500 г йогырт.

Җиләкләрнең бер өлешен блендер ярдәмендә изәргә, калганын турарга кирәк. Тирән савытта җиләкле измә, куертылган сөт һәм йогыртны бергә кушып, болгатырга. Шуның өстенә җиләк кисәкләрен тезәргә. Әлеге массаны махсус формаларга (яисә капкачлы контейнерга) салырга, төнгә туңдыргычта калдырырга.

Табынга бирер алдыннан туңдырманы бизәргә дә була.

Башыңны эшләт!

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7043 данә
Гомуми тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 209

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+